

Инсар районында бердән-бер кечкенә генә Яндовище дигән татар авылы бар. Анда торле милләтле 119 кеше дус яши. Авылны халкы яшәтергә тели. Шулай, Яндовище мәдәният хезмәткәрләре Мәдәният йортларынын һәм китапханәләренен торышын яхшырту турында кайгырталар. Мәсәлән, авыл Мәдәният йорты модире Н.А.Бикмаева клубларынын залында һәрвакыт унайлы, матур булсын очен барысын да эшли. Монда чәчәкләр кvп, алар торле чаралар vткән вакытта аерым атмосфера тудыралар. Яндовищелылар vтенече буенча, авылга кvптән тvгел татар жырларын башкаручы Нуржихан (Н. Симаева (Умряева) – Н.Дусметова вокал студиясе солисткасы килгән. Жырчы Мордовиядә, Татар Ымызы авылында, комбайнчы гаиләсендә туган. Кечкенәдән vк гармунда уйный, кvнелле такмаклар ижат итә. Сонрак инде житди әсәрләр яза. Яндовищега килгән танылган татар жырчысы Нуржихан жирле мәдәният хезмәткәрләре эшенә югары бәя биргән һәм яндовищелылар очен яна концерт бирергә вәгъдә иткән. Милли тарих, мәдәният, әдәбият турында кvп мәгълумат туплап килvче китапханәче В.Н.Сыроватский vз эшенә яналыклар кертә. Яндовищеда китап фондын саклыйлар, еш кына кызыклы чаралар vткәрәләр. Хәзерге вакытта Боек Жинvнен 75 еллыгына әзерлек бара инде. Мәдәният хезмәткәре vз коче белән авыл музеена ремонт ясый; анда авыл тарихы, авыл халкынын конкvреше, танылган авыл кешеләре турында кvпторле экспонатлар тупланган. Боек Ватан сугышында Яндовище халкынын катнашуы турында сойләvче материаллар аерым урын алып тора. Фронтовиклар турындагы фотоматериалларны кадерләп карыйлар. Рәсемнәрне мәктәп укучылары берничә дистә ел гына жыймаган. Авыл ветераннары, яшьләр белән очрашулар вакытында, сугышларда катнашучыларнын тыныч вакыттагы тормыш һәм хезмәт эшчәнлеге турында сойлиләр.

– Безнен авыл зур тvгел, - ди мәдәният хезмәткәре Нина Александровна Бикмаева. – Әмма авыл халкыбыз мәдәният учагында vткәрелгән чараларны ярата. Шуны да билгеләп vтәргә кирәк, яндовищелыларнын бай мәдәни традицияләре бар. Ә без милли авылыбыз мирасын саклап калырга гына тvгел, арттырырга да тырышабыз.

Биредә кече Ватаныбызнын чын патриотлары яши. Алар бер-берсен хормәт итәләр, олкәннәргә хормәт белән карыйлар. Яндовищеда кунак-ларга һәрвакыт шат.